
Мордовиядә быел су басу куркынычы апрельнен беренче декадасында котелә. Бу хакта язгы ташкынга әзерләнvгә багышланган матбугат конференциясендә хәбәр иттеләр. Мордовия Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы vзәге житәкчесе Светлана Левина быел март кышкы режимда кала, ә актив кар эреvе апрель башында гына башланачак, дип сойләде. Әгәр дә янгырлар кvп булган жылы һава массалары vтеп керсә, барлык кар запаслары эри, бу елгаларда су дәрәжәсенен тиз кvтәрелvенә һәм якын-тирәдәге торак пунктларны су басуга китерәчәк.      Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгынын Мордовия Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы Сергей Репин киләсе сезоннын житдилеген билгеләп vтте һәм ул гадәттән тыш хәлләргә китерергә момкинлеген әйтте. Ул су басу куркынычы булган чорга әзерлек чаралар оештырылган дип матбугат конференциясендә белдерде. Тагы, эрегән чорда сулыкларнын бозда булу куркынычын аерым ассызыклады. Ул балык тоту союченләрне сак булырга һәм бозга чыгудан сакланырга чакырды. Ата-аналарга балаларнын вакытларын контрольдә тотарга һәм аларга язгы куркынычсызлык кагыйдәләрен анлатырга куштылар.
Мордовия Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча дәvләт комитеты рәисе Андрей Наумов профилактик чаралар vткәрv турында хәбәр итте. Хужасыз гидротехник корылмалар даими хезмәт кvрсәтә һәм ремонтлана. Аерым алганда, сонгы 10 елда аларнын саны 130 дан 6 га кадәр кимегән.
Су басу вакытында 2800 коткаручы, 1000 берәмлек техника һәм 100дән артык йозv чарасы хезмәткә әзер.
Матбугат конференциясе барышында шулай ук, коткару хезмәтләренен техник жиһазлануын кочәйтv һәм барлык кызыксынган ведомстволар арасында vзара хезмәттәшлек мәсьәләләре каралды.
“Язгы боз ястык калынлыгы булса да, ышанма”, – ди халык. Чыннан да, козге боз кеше авырлыгыннан чатный башлый, ә язгы боз кеше баскан жирдә туп-турыга ишелеп кенә тошә. Язгы ташулар якынлашкан саен, авыл халкынын мәшәкате бермә-бер арта: ой тvбәсендәге карны вакытында чистартырга, су нигезгә китмәсен очен ой тирәсендәге карны корәп, канау казырга, малларны куркынычсыз урынга кvчерv очен урын әзерләргә, эчәр су, азык-толек, медикаментлар запасы булдырырга кирәк. Ялгыз яшәvче ярдәмгә мохтаж кешеләрне, олкән яшьтәге әби-бабайларны да игътибардан читтә калдырырга ярамый. Учреждение һәм оешмалар житәкчеләренә эш урынындагы биналарнын тvбәсен, тирә-юнен кардан чистартырга тәкъдим ителә.
Бик моһим әйберне онытмагыз. Язгы суга эләккәндә ин беренче ос киемнәреннән котылырга тырышыгыз, алар сезне инде жылытмый, ә бәлки су белән авыраеп аска сойри. Шунысын да истә тотыгыз, чыныкмаган кеше, температурасы 0 градус чамасы булган суда 10–15 минут чамасы торса, анын жуярга момкин. Шуна да судан чыккан кешегә тиз генә коры киемнәр бирергә, баллы әйбер ашатырга һәм, ул тәмам жылынып житкәнче, актив хәрәкәтләндерергә кирәк.
Язгы чорда балаларнын хәвеф-сезлегенә карата аеруча игътибарлы булырга кирәк. Аларга сулыклар, елга-кvлләр янында уйнаунын хәвефле булуын анлатырга һәм анда

vзләрен генә жибәрмәскә кирәк.

**Наилә НАСЫРОВА**